**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Аксубай шәһәр тибындагы бистәсе Советы**

**КАРАР**

**№ 49** **15 февраль 2018 ел**

**Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башлыгының 2017 елда шәһәр җирлегенең социаль-икътисади үсеше йомгаклары һәм 2018 елга фараз турында хисабы**

Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башлыгының 2017 елгы социаль – икътисади үсеш йомгаклары һәм 2018 елга фараз турында хисабын тыңлап һәм фикер алышып. Депутатлар билгеләп үткәнчә, Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Советы эшчәнлеге 2017 елда поселок халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә, поселок Советы тарафыннан гамәлгә ашырылган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы:

1. Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башлыгының 2017 елда шәһәр җирлегенең социаль – икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.
2. 2018 елда шәһәр җирлегенең социаль – икътисади үсешенең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.
3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.
4. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.
5. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
6. Аксубай шәһәр тибындагы бистәсен төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.
7. Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.
8. Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.
9. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru.
10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр тибындагы Аксубай поселогы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Аксубай муниципаль районы Советы Рәисе К.К.Гилманов

СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА АКСУБАЕВО